**Татарстан Республикасы Президенты Указы**

**Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениеләре студентларына дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында**

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениеләренең укучыларның бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларының йомгаклау этабында җиңүчеләрдән һәм бүләк алучылардан булган студентларына өстәмә дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениеләре көндезге уку бүлекләренең укучыларның бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларының йомгаклау этабында җиңүчеләрдән һәм бүләк алучылардан булган студентлары өчен Татарстан Республикасы Президентының 100 стипендиясен гамәлгә куярга, шул исәптән:

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче студентлар өчен – 50 стипендия;

Россия Федерациясенең бүтән субъектларыннан килгән студентлар өчен – 50 стипендия.

2. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениеләре көндезге уку бүлекләренең укучыларның бөтенроссия һәм халыкара олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләк алучыларыннан булган студентлары өчен Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре (алга таба шулай ук – Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре) федераль дәүләт югары уку йортларының көндезге уку бүлекләрендә һәм федераль бюджет акчалары исәбеннән белем алучы студентлары өчен федераль законнарда билгеләнгән стипендиянең бишләтелгән күләмендә түләнә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениеләре көндезге уку бүлекләренең укучыларның бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларының йомгаклау этабында җиңүчеләрдән һәм бүләк алучылардан булган студентлары өчен Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре турындагы нигезләмәне расларга (кушымтада бирелә).

4. Татарстан Республикасы Президенты стипендиясен алучылар, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениеләрендә белем алуларын тәмамлаганнан соң, алга таба Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Алгарыш» грантлар программасы буенча Россиянең һәм чит илләрнең әйдәүче мәгариф үзәкләрендә белем алуга яисә стажировка узуга өстенлекле хокукка ия була, дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджет акчалары исәбеннән финанслауны тәэмин итәргә;

тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда Татарстан Республикасы Президентының әлеге Указ нигезендә гамәлгә куелган стипендияләрен түләү өчен бюджет ассигнованиеләрен күздә тотарга, шулай ук әлеге Указны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

6. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары шурасы белән берлектә, укучыларның бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларында җиңүчеләрне һәм бүләк алучыларны Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан әйдәүче дәүләт югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләрендә белем алуга җәлеп итү буенча тиешле эш уздыруны тәэмин итәргә.

7. Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары шурасының Татарстан Республикасы Президенты стипендиясен алучы студентларга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тиешле дәүләт югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләренең тулай торакларында урын бирү тәртибе турындагы инициативасын хупларга.

8. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2010 ел, 21 декабрь
№ ПУ-835